БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.10.2022 Баулы шәһәре №69

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 89 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 139 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 44 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 2 һәм 3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи окладына карата берничә мәртәбә исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи окладлы күләме 11 958 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров